

Мордовия Республикасында, ботен илдәге кебек vк, 22 июньдә Хәтер һәм кайгы конендә багышланган тантаналар узды. Бу дата ил тарихында һәм кешеләр хәтерендә ин кайгылы һәм фажигале дата буларак кала. 85 ел элек 27 миллион кешенен гомерен озгән Боек Ватан сугышы башланды. Халыкнын героик батырлыгы киләчәк буыннар хәтерендә мәнгегә сакланырга тиеш.

1941-1945 еллардагы Боек Ватан сугышында һәлак булган Мордовия сугышчылары һәйкәленә чәчәкләр салу тантанасында Мордовия Главасы Артём Алексеевич Здунов катнашты.
Монументка шулай ук Мордовия Госсобраниесы, Республика Хокvмәте, РФ Президентынын Идел буе федераль округындагы Тулы вәкаләтле вәкиле аппараты, Мордовия Республикасы Главасы администрациясе һәм Мордовия Республикасы Хокvмәте, Саранск шәһәр округы житәкчесе, хәрби хезмәткәрләр һәм хокук саклау органнары житәкчеләре, Россия Геройларынын тол хатыннары, ижтимагый, ветеран һәм хәрби-патриотик оешмалар, кадетлар һәм гомуми белем бирv оешмалары яшь армиячеләре чәчәкләр салды.



Ватанны фашизмнан саклап, изге бурычын vз гомерләре бәрабәренә vтәгәннәрнен барысын да бер минут тынлык белән искә алдылар. Ахырда оч тапкыр мылтык залпы һәм Россиянен Дәvләт гимны янгырады. Бу жимергеч, рәхимсез һәм канкойгыч сугыш турындагы хатирәләр, тынгысыз кайгы кебек, vзебез яшәгән донья очен гомерләрен биргән миллионлаган солдатнын балалары һәм оныклары кvнелендә мәнгегә калачак.
Махсус хәрби операция геройлары һәйкәленә чәчәкләр салдылар.
Мордовиянен һәрбер почмагында Хәтер һәм кайгы конендә багышланган чаралар vтте. Саранскида «Бердәм Россия» активистлары һәм тарафдарлары, алдан тавыш бирvдә катнашучылар һәм жинvчеләр, яшь гвардиячеләр, шулай ук рес-публиканын торле яшьләр оешмалары вәкилләре һәм шәһәрлеләр истәлекле инсталляция булдыру очен берләштеләр. Акциядә катнашучылар асфальтка хәрби батырлыкнын топ символын - vз

гомерләре бәрабәренә кvптән котелгән Жинvне алып килгән Боек 

Ватан сугышы геройлары истәлегенә биш очлы ал йолдыз куйдылар.
- Боек Ватан сугышы - ин рәхимсез һәм фажигале. 1418 кон һәм тон безнен сугышчылар батырларча сугыштылар, жинvне якынайттылар. Тылда да - балалар, картлар, предприятиеләрдә һәм авыл хужалыгында эшләvче, гуманитар ярдәм жыеп фронтка озатучы хатын-кызлар - 1418 кон һәм тон Жинv яуладылар. Бу сугыш һәр торак пунктка, һәр гаиләгә кагылды.
Бvгенге акцияне уздырып, сугыш кырларында калган, яраланып кайткан һәм респуб-ликабыз хакына хезмәт итvен дәвам иткән барлык кешеләрне исемләп искә алу бик моһим», - дип билгеләп vтте Мордовия Республикасы Хокvмәте Рәисенен беренче урынбасары Галина Алексеевна Лотванова.
Шәмнәр махсус хәрби операциядә һәлак булган катнашучылар истәлегенә дә кабынды. Чарада катнашучыларга сынаулар алдында бердәмлек һәм рух коченен әһәмияте турында искә тошерде. Һәлак булганнарны бер минут тынлык белән искә алдылар. Акция Боек Ватан сугышы елларында һәлак булган Мордовия сугышчылары монументы итәгенә чәчәкләр салу белән тәмамланды.



Жинv мәйданында «Хәтер вахта-сы-1 нче Пост» оештырылган иде. Боек Ватан сугышы елларында һәлак булган Мордовия сугышчылары мемориалы янындагы мактаулы каравылга Мордовиянен «Поиск» республика патриотик берләшмәсе балалары, фашизмга каршы корәштә һәлак булган Ватанны саклаучыларнын батырлыгы истәлегенә, мактаулы вахта алып бардылар.
22 июньдә, ботен Ил белән бергә, «Сура рубежы» мемореаль комплексында, Ләм-берә районы һәм һәрбер авылы халкы, Ромоданово районы Алтар, Белозерье мәктәпләре укучылары Гомумроссия ак-циядә катнашып, батырларны искә алдылар.  Әйтеп китәргә кирәк, бу конгә Мордовия авылларында һәйкәлләр янартылды, чистартылды.
Рузаевка районы Татар Пешлә авылында бу конне тантаналы «Һәлак булганнар истәлеге» митингы vтте. Кадошкино районы Латышовка урта мәктәбенен «Кояшлы нурлар» жәйге ял лагеренда һәлак булган сугышчылар обелискына чәчәкләр салу - истәлекле чара узды. Балалар, тәрбиячеләре белән бергә, киләчәгебез очен гомерләрен биргән геройларны искә алдылар. Бер минут тынлыкта һәр-кем тирән рәхмәт һәм кайгы тойды, ата-бабаларыбызнын батырлыгына хормәт кvрсәтте. 1941 елнын 22 нче июнендәге фажигале вакыйгалар истәлегенә балалар очен «Беркем дә онытылмады, бер-нәрсә дә онытылмады» батырлык дәресе vткәрелде: балалар ата-бабаларыбызнын батырлыгы һәм тарихи хәтерне саклаунын моһимлеге турында белделәр. Чара кысаларында Боек Ватан сугышы турында шигырьләр һәм хикәяләр укылды - кvнелне нечкәртә торган юллар барлык катнашучыларнын йорәкләренә тирән vтеп керде. Шулай ук «Безгә тынычлык кирәк» рәсемнәр конкурсы да vткәрелде. Яшь рәссамнар vз эшләре аша тынычлыкка омтылуларын һәм безгә баш остендә тыныч кvк бvләк иткән геройларга рәхмәтләрен белдерделәр. Бу кон балаларга доньянын кыйммәтен анларга һәм

Ватаныбызны саклаучыларга хормәт кvрсәтергә ярдәм итте.
Ә 21 июньдә Темников районы «Тархановский» авыл клубы белән китапханә хезмәткәрләре, яшьләр һәм балалар «Хәтер шәме» акциясенә кушылды. Шул ук районнын «Митряловский», Аксел авыл клублары хезмәткәрләре, яше-карты «Хәтер шәме» акциясендә катнашты. Кочкурово районы Татар Умыс авыл китапханәсе «Хәтер шәме» онлайн - акциясенә кушылды, Татар Умыс халкы һәйкәлләре янындагы митингта булды. Акциядә катнашучылар Ватан очен гомерләрен биргәннәргә рәхмәтләрен һәм ихтирамнарын белдерv очен һәйкәлләр янында шәмнәр кабыздылар, чә-чәкләр бәйләме салдылар.
Мордовиядә беркем дә һәм бернәрсә дә онытылмады!

**Наилә НАСЫРОВА**